


***Габдулла Тукай***

*(1886—1913)*

Әгәр дә дөньяда бик аз яшәп тә, күп эшләр эшләп киткән язучылар турында сүз бара икән, аның берсе, һичшиксез, Габдулла Тукай булыр. Аңа бит үлгәндә нибары егерме җиде яшь кенә була. 1886 нчы елның апреле һәм 1913 нче елның апреле. Яз аенда туган, яз аенда үлгән...





Мухамметгариф, отец Г.Тукая



Бибимамдуда, мать Г.Тукая

Шагыйрьнең туган ягы — матур табигатьле Казан арты. Ул 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә хәзерге Арча районының Кушлавыч авылында туа. Әтисе мулла була. Габдуллага дүрт ай ярым булуга, ул үлә. Әнисе, аны Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча калдырып, Сасна авылы (Балтач районы) мулласына кияүгә чыга. Менә шуннан шагыйрьнең авыр тормышы башлана. Габдулла авыр язмыш кичерә: ятимлек, фәкыйрьлек, кимсетүләр...





Группа шакирдов медресе "Мутыгия".
Второй справа в первом ряду - Г.Тукай



Г.Тукай, С.Рамиев, Ш.Гайфи. Астрахань, 1911.

1895 нче елны Габдулланы әтисе ягыннан апасы Уральск шәһәренә алдыра. Анда ул мәдрәсәдә һәм бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә укый. Мәдрәсәдә гарәп, төрек, фарсы телләрен бик яхшы үзләштерә, рус телен дә өйрәнә. Бу аңа Европа әдәбияты белән танышырга мөмкинлек бирә. Габдулла Тукай 1907 нче елның көзенә чаклы Уральскида яши, аннан Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казанда була.





5 1 (2) апрельдә бөек шагыйребезнең гомере өзелә.Тукай 27 ел гына яшәсә дә, искиткеч зур әдәби мирас калдырды, халыкка хезмәт итүнең бөек үрнәген бирде.

